| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 нче март 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының
«Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
башкарма комитетына кергән гражданнарның
мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2007 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауны үткәрү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.З.Хабибуллин

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 11 мартындагы 2 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе.

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының " Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, җәмәгатьчелек фикерен һәм гражданнарның актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау барлык мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән язма рәвештә дә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү юлы белән электрон документ рәвешендә, шулай ук гражданнарны вәкаләтле затлар тарафыннан шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен гамәлгә ашырыла.

5. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты секретаре хисап чорыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә гражданнарны шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнар шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турындагы мәгълүмат (булган очракта) булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда алдагы елның шушы чорына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрел.

8. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты секретаре, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 числосына кадәр «Авыл җирлекләре» бүлегендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ел саен аналитик белешмә урнаштыруны тәэмин итә.